**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 сентября 2016 года

**Статья 1**

Внести в Бюджетный кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II часть), № 10 (I часть), № 12 (IV часть); 2006, № 6 (I часть), № 12 (I часть); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III часть), № 10 (I часть); 2009, № 7 – 8 (I часть), № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (I часть); 2011, № 8 (I часть), № 11 (I часть), № 11 (II часть); 2012, №11 (I часть); 2013, № 7, № 10, № 11 (I часть); 2014, № 5, №12 (III часть); 2015, № 7 (I часть), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III часть) следующие изменения:

1) пункт $3^1$ статьи 25 дополнить абзацем следующего содержания:

«другие операции по управлению остатками средств на едином счете по учету средств бюджета Республики Татарстан (при условии соответствия Республики Татарстан требованиям, установленным абзацем первым пункта 2 статьи 236 Бюджетного кодекса Российской Федерации), осуществляемые в порядке, установленном Кабинетом Министров Республики Татарстан.»;

2) в пункте 3 статьи $47^1$ слова «Федеральной службой финансово-бюджетного надзора в целях осуществления ею» заменить словами «Федеральным казначейством в целях осуществления им»;

3) в статье 49:

а) дополнить новым абзацем сорок четвертым следующего содержания:

«утверждает типовую форму соглашений о предоставлении предусмотренных пунктом 1 статьи $78^1$ Бюджетного кодекса Российской Федерации субсидий бюджетным или автономным учреждениям Республики Татарстан;»;

б) абзац сорок четвертый считать абзацем сорок пятым;

4) в пункте 4 статьи 97:

а) в абзаце первом слова «, из которого они были ранее предоставлены,» заменить словами «Республики Татарстан»;

б) в абзаце третьем слова «межбюджетных трансфертах, предоставленных в форме субсидий и иных межбюджетных трансфертов, имеющих целевое назначение, не использованных в отчетном финансовом году, а также возврат указанных межбюджетных трансфертов» заменить словами «указанных в абзаце первом настоящего пункта межбюджетных трансфертах, не использованных в отчетном финансовом году, а также их возврат»;

в) абзац четвертый изложить в следующей редакции:

«В соответствии с решением главного администратора средств бюджета Республики Татарстан о наличии потребности в межбюджетных трансфертах, полученных в форме субсидий, субвенций и иных межбюджетных трансфертов, имеющих целевое назначение, не использованных в отчетном финансовом году, согласованным с Министерством финансов Республики Татарстан в определяемом им порядке, средства в объеме, не превышающем остатка указанных межбюджетных трансфертов, могут быть возвращены в текущем финансовом году в доход бюджета, которому они были ранее предоставлены, для финансового обеспечения расходов бюджета, соответствующих целям предоставления указанных межбюджетных трансфертов.»;

г) дополнить новым абзацем пятым следующего содержания:

«Порядок принятия решений, предусмотренных абзацем четвертым настоящего пункта, устанавливается нормативным правовым актом Кабинета Министров Республики Татарстан, регулирующим порядок возврата межбюджетных трансфертов из бюджета Республики Татарстан.»;

д) абзац пятый считать абзацем шестым;

5) в статье 100:

а) наименование дополнить словами «при санкционировании операций»;

б) абзац первый пункта 1 после слов «финансового контроля» дополнить словами «при санкционировании операций»;

в) пункт 2 признать утратившим силу;

6) в пункте 2 статьи 101:

а) абзац первый дополнить словами «, а также стандартами осуществления внутреннего государственного финансового контроля»;

б) дополнить абзацем следующего содержания:

«Стандарты осуществления внутреннего государственного финансового контроля утверждаются Министерством финансов Республики Татарстан в соответствии с порядком осуществления полномочий Министерством финансов Республики Татарстан по внутреннему государственному финансовому контролю,

определенным нормативными правовыми актами Кабинета Министров Республики Татарстан.».

**Статья 2**

Абзац седьмой пункта 50 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 16 октября 2013 года № 79-ЗРТ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан и отдельные законодательные акты Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 10; 2014, № 11 (I часть) признать утратившим силу.

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ *
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
23 сентября 2016 года
№ 64-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 25 статьяның $3^1$ пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын исәпкә алу буенча бердәй счетта калган акчалар белән идарә итү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган башка операцияләр (Татарстан Республикасы Россия Федерациясе Бюджет кодексының 236 статьясындагы 2 пунктының беренче абзацында билгеләнгән таләпләргә туры килгән очракта).”;

2) $47^1$ статьяның 3 пунктында “Федераль финанс-бюджет күзәтчелеге хезмәте тарафыннан” сүзләрен “Федераль казначылык тарафыннан” сүзләренә алмаштырырга;

3) 49 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа кырык дүртенче абзац өстәргә:

“Татарстан Республикасының бюджет яисә автоном учреждениеләренә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктында каралган субсидияләрне бирү турындагы килешүләрнең типлаштырылган рәвешен раслый;”;

б) кырык дүртенче абзацны кырык бишенче абзац дип санарга;

4) 97 статьяның 4 пунктында:

беренче абзацта “үзләре алынган бюджет” сүзләрен “Татарстан Республикасы бюджеты” сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче абзацта “максатчан билгеләнештәге субсидияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, финанс хисабы елында файдаланылмый калган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булуы (булмавы) турында карар кабул итү, шулай ук бу бюджетара трансфертларны үзләре алынган бюджетка кире кайтару” сүзләрен “финанс хисабы елында файдаланылмый калган, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булуы (булмавы) турында карар кабул итү, шулай ук аларны үзләре алынган бюджетка кире кайтару” сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы бюджеты акчалары баш администраторының, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә аның белән килештерелгән, финанс хисабы елында файдаланылмый калган максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә күрсәтелгән бюджетара трансфертларның калган акчаларыннан артык булмаган күләмдәге акчалар бюджетның әлеге бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен агымдагы финанс елында үзләре элек бирелгән бюджет кеременә кире кайтарылырга мөмкин.”;

г) түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче абзац өстәргә:

“Әлеге пунктның дүртенче абзацында каралган карарларны кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертларны кире кайтару тәртибен җайга сала торган норматив хокукый акты белән билгеләнә.”;

д) бишенче абзацны алтынчы абзац дип санарга;

5) 100 статьяда:

а) исемендә “Татарстан Республикасы” сүзләре алдыннан “Операцияләрне санкцияләгәндә” сүзләрен өстәргә;

б) 1 пунктның беренче абзацында “Татарстан Республикасы” сүзләре алдыннан “Операцияләрне санкцияләгәндә” сүзләрен өстәргә;

в) 2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

6) 101 статьяның 2 пунктында:

а) беренче абзацта “актлары” сүзеннән соң “, шулай ук эчке дәүләт финанс контролен үткәрү стандартлары” сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Эчке дәүләт финанс контролен үткәрү стандартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының эчке дәүләт финанс контролен үткәрү

вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан раслана.”.

**2 статья**

“Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2013 елның 16 октябрендәге 79-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 50 пунктының җиденче абзацын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 10; 2014, № 11 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 23 сентябре
№ 64-ТРЗ